КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 1 октябрь г.Казань № 846

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 16 май, 596 нчы карары белән расланган Су мөнәсәбәтләре өлкәсендә Россия Федерациясенең аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен финанс белән тәэмин итү чыганагы булып федераль бюджеттан субвенцияләр торган башка максатларга «Геология һәм Татарстан Республикасы җир асты байлыкларыннан файдалану буенча фәнни-җитештерү берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Су мөнәсәбәтләре өлкәсендә Россия Федерациясенең аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен финанс белән тәэмин итү чыганагы булып федераль бюджеттан субвенцияләр торган башка максатларга «Геология һәм Татарстан Республикасы җир асты байлыкларыннан файдалану буенча фәнни-җитештерү берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында» 2023 ел, 16 май, 596 нчы карары белән расланган Су мөнәсәбәтләре өлкәсендә Россия Федерациясенең аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен финанс белән тәэмин итү чыганагы булып федераль бюджеттан субвенцияләр торган башка максатларга «Геология һәм Татарстан Республикасы җир асты байлыкларыннан файдалану буенча фәнни-җитештерү берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибенә, түбәндәге эчтәлекле 20 пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«20. Субсидия бирү һәм субсидияләр бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чара тәмамлану фактын чагылдыра торган вакыйгалар (контроль нокта) нәтиҗәсе күрсәткечләренә ирешү мониторингы Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә уздырыла.».

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин